**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 23 декабрь | № 978

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2016 ел, 14 март, 138 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2016 ел, 14 март, 138 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 23 июнь, 428 нче; 2016 ел, 31 август, 605 нче; 2016 ел, 26 октябрь, 779 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган 2016 елга финанслау күләмнәрен агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен бүлүдә:

1 нче пунктта «1 715 551,1» саннарын «1 712 051,1» саннарына алмаштырырга;

12 нче пунктта «198 022,6» саннарын «211 411,5» саннарына алмаштырырга;

13 нче пунктта «144 535,9» саннарын «140 147,0» саннарына алмаштырырга;

16 нчы пунктта «314 488,4» саннарын – «313 488,4» саннарына, «2 000,0» саннарын «1 000,0» саннарына алмаштырырга;

18 нче пунктта «127 740,3» саннарын – «123 240,3» саннарына, «62 000,0» саннарын «57 500,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2016 елда үсемлекчелек өлкәсендә бәйләнмәгән ярдәм күрсәтү өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә кушымтада:

«Ашлыкка кукуруза, рапс, көнбагыш, кытай борчагы җитештерүне стимуллаштыру» юлында «83 602,1» саннарын «80 102,1» саннарына алмаштырырга;

«Барлыгы» юлында «1 715 551,1» саннарын «1 712 051,1» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2016 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибендә:

5 нче пунктта:

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«йорт куяннарының нәселле баш санын асрауга субсидияләр бирү;»;

ундүртенче һәм унбишенче абзацлар үз көчен югалткан дип санарга;

17 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Йорт куяннарының нәселле баш санын асрауга субсидияләр нәсел заводларына һәм нәсел репродукторларына 2016 елның 1 октябре хәленә карата бер башка 148,0 сум исәбеннән бирелә.

Нәсел заводларына һәм нәсел репродукторларына йорт куяннарының нәселле баш санын асрау өчен субсидияләр бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

нәсел заводларының һәм нәсел репродукторларының дәүләт нәсел регистрында теркәлү турында таныклыгы булу;

йорт куяннарының нәселле баш саны булу;

2017 елның 1 гыйнвары хәленә карата йорт куяннарының нәселле баш санын саклау турында йөкләмә.

Субсидия алу өчен нәсел заводлары һәм нәсел репродукторлары Идарәгә түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза;

Россия Федерациясенең Статистика буенча дәүләт комитеты тарафыннан расланган форма буенча 2016 елның сентябренә фермада терлек һәм кош-корт хәрәкәте турында хуҗалык эчендәге хисап күчермәсен;

2015 ел өчен рәсми статистика хисабы аның нигезендә төзелгән терлекчелек торышы турында мәгълүмат;

бирелергә тиешле субсидия турында Министрлык раслаган форма буенча белешмә-исәп-хисап.»;

19 нчы һәм 20 нче пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге Тәртипкә кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

әлеге карар белән расланган 2016 елда сөтчелек юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлеккә булышлык күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибендә:

бу Тәртипкә 1 нче кушымтада:

1 нче пунктта «40 074,7» саннарын «41 307,5» саннарына алмаштырырга;

2 нче пунктта «9 100,0» саннарын «8 300,0» саннарына алмаштырырга;

3 нче пунктта «48 065,2» саннарын «45 098,9» саннарына алмаштырырга;

4 нче пунктта «47 296,0» саннарын «45 440,6» саннарына алмаштырырга;

«Барлыгы» юлында «144 535,9» саннарын «140 147,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

2016 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 23 декабрь, 978 нче карары редакциясендә)

2016 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен акча бүлү

| Т/с | Статьялар исеме | Финанслау күләме, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле ана баш санын асрауга субсидияләр | 14 278,8 |
| 2. | Нәсел үрчеткеч ата дуңгызлар асрауга субсидияләр | 2 700,0 |
| 3. | Нәселле авыл хуҗалыгы хайваннары сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр | 755,8 |
| 4. | Итле токымнан булган нәсел үрчеткеч нәселле үгезләр җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 3 000,0 |
| 5. | Итле токымнан булган нәселле мөгезле эре терлекнең баш санын арттыруга чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 501,0 |
| 6. | Нәсел үрчеткеч ата дуңгызлар орлыгын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 3 785,1 |
| 7. | Мөгезле эре терлектән булган бозаулар үрчеме өчен хайваннарны ясалма орлыкландыру операторларына субсидияләр | 35 444,5 |
| 8. | Балык үрчетү материалы сатып алу чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 2 706,0 |
| 9. | Авыл хуҗалыгы хайваннарын ясалма орлыкландыруга инструментлар һәм җиһазлар сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 17 229,4 |
| 10. | Нәселле кәҗәләр сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 5 185,4 |
| 11. | Йорт куяннарының нәселле баш санын асрауга субсидияләр | 10 000,0 |
| 12. | Үрдәкләр сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 1 928,5 |
| 13. | Чиста канлы менге токымнан булган атлар асрауга чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 3 907,2 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 14. | Нәселле атлар сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр | 15 000,0 |
| 15. | Чиста канлы менге токымнан булган нәсел атлары һәм юртаклар тренингы һәм аларны сынау чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 7 000,0 |
| 16. | Нәсел үрчеткеч айгырлар орлыгын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 3 000,0 |
| 17. | Яңадан төзелгән гаилә терлекчелек фермаларына сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлек сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 1 116,2 |
| 18. | Сөтле токымнан булган нәселле мөгезле эре терлек җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 83 873,6 |
| Барлыгы | | 211 411,5 |

____________________________

2016 елда сөтчелек юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлеккә булышлык күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 23 декабрь, 978 нче карары редакциясендә)

2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең сөтчелек юнәлешендәге нәселле мөгезле яшь эре терлек сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә финанслау лимитларын
Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

| Т/с | Муниципаль район исеме | Финанслау лимиты, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Әгерҗе | 3 240,3 |
| 2. | Азнакай | 981,4 |
| 3. | Актаныш | 271,3 |
| 4. | Алексеевск | 4 035,6 |
| 5. | Әлки | 3 367,5 |
| 6. | Әлмәт | 483,6 |
| 7. | Арча | 1 745,6 |
| 8. | Әтнә | 1 178,9 |
| 9. | Балтач | 272,7 |
| 10. | Югары Ослан | 1 428,8 |
| 11. | Биектау | 2 616,1 |
| 12. | Чүпрәле | 107,5 |
| 13. | Зәй | 841,8 |
| 14. | Зеленодольск | 6 938,5 |
| 15. | Кукмара | 4 123,9 |
| 16. | Лениногорск | 107,1 |
| 17. | Мамадыш | 4 487,4 |
| 18. | Минзәлә | 207,1 |
| 19. | Түбән Кама | 1 698,0 |
| 20. | Яңа Чишмә | 60,4 |
| 21. | Питрәч | 1 323,3 |
| 22. | Балык Бистәсе | 479,1 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 23. | Саба | 1 599,6 |
| 24. | Спас | 91,2 |
| 25. | Тәтеш | 396,4 |
| 26. | Тукай | 2 253,6 |
| 27. | Теләче | 81,9 |
| 28. | Чирмешән | 468,6 |
| 29. | Чистай | 211,7 |
| Барлыгы | | 45 098,9 |

F:\KARAR\2016\978_2.doc